**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**12 май 2026 ел** **№ 26**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының «Менделеевск
муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге
территориясендә җәмәгать зиратлары эшчәнлеге тәртибен
һәм җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләрен раслау турында»
2022 елның 8 февралендәге 50 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы федераль законнарга туры китерү максатларында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының «Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясендә җәмәгать зиратлары эшчәнлеге тәртибен һәм җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләрен раслау турында»2022 елның 8 февралендәге 50 нче номерлы карарына (алга таба- карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: 1.1. Карарның 2 статьясындагы 2.2 пунктының 1 абзацында 1 нче кушымтада (православие) сүзен (җәмәгать) сүзенә алыштырырга.

1.2. Карарның 2 нче кушымтасында 3 статьяның 3.2 пунктындагы 6 абзацын тексттан төшереп калдырырга

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча www.mendeleevsk.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы рәисе Т.П.Кузнецова